**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2025 Балык Бистәсе штп. №235пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының айлык хезмәт хакы һәм шундый муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең айлык хезмәт хакы нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын хезмәт хакы һәм премияләү турында нигезләмәләрне раслау хакында» 01.02.2017 №16пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәтенә түләүне тәртипкә китерү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре эшенең нәтиҗәлелеген арттыруны стимуллаштыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 24.04.2025 №540 карары нигезендә «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының айлык хезмәт хакы һәм шундый муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең айлык хезмәт хакы нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе турында һәм Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын хезмәт хакы һәм премияләү турында нигезләмәләрне раслау хакында» 01.02.2017 №16пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.5 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында 24.12.2007 ел, №922 карары белән расланган уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында нигезләмә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24.04.2025 ел, №540 карары белән расланган уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибенең үзенчәлекләре турында нигезләмә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Д.Р. Потаповага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов